КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 апрель г.Казань № 216

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләүне оештыру турында» 2016 ел, 20 май, 331 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләүне оештыру турында» 2016 ел, 20 май, 331 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 07 июль, 463 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында» 2003 ел, 4 сентябрь, 547 нче» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге нигезләмәне раслау турында» 2020 ел, 18 сентябрь, 1485 нче» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «укытуны оештыру турында» сүзләрен «әзерләү турында» сүзләренә, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында» 2003 ел, 4 сентябрь, 547 нче карары белән расланган табигый һәм техноген характердагы

гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында нигезләмә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 ел, 18 сентябрь, 1485 нче карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәге» белгечләренең квалификациясен күтәрү максатларында Татарстан Республикасының дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә өстәмә һөнәри белем бирү» сүзләрен «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәге» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт бюджет учреждениесендә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин